# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Зирекле авыл торак пунктында
2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2022 елның 12 октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Зирекле авыл торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Зирекле авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
   - авыл эчендәге юлларны карап тоту;
   - авыл эчендәге юлларны ремонтлау;
   - торак пунктларда урам утларын карап тоту;
   - су челтәрләрен карап тоту;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Зирекле авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Зирекле авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы _______________ Данилова В.А.
( имза )

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ ЕРЫКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ